**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет муниципального образования «поселок городского типа Актюбинский» Азнакаевского муниципального района**

ул. Губкина, д. 24, п.г.т. Актюбинский, Азнакаевский муниципальный район, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

Губкин урамы, 24 йорт, Актүбә ш.т.п., Азнакай муниципаль районы, 423304
тел. (факс): (85592) 3-16-63
E-mail: Svetlana.Strukova@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» март 2021 ел № 18

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының кайбер карарлары үз көчен югалтуын тану турында

Норматив хокукый актларның гамәлдә булу срогы тәмамлануга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Актүбә шәһәр тибындагы поселок" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип таныргa:

- 2020 елның 29 декабрьдәге 137 номерлы «Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге бюджетыннан «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Иске Актүбә микрорайонында күперне ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында»;

- 2020 елның 29 декабрьдәге 138 номерлы «Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге бюджетыннан «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Мирная, Овражная, Светлая урамнарында, шулай ук Полигон ТБО территориясенә һәм Промзона буйларындагы тротуарларны чистарту буенча эшләрен башкаруга бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү тәртибе турында»;

- 2020 елның 29 декабрьдәге 139 номерлы «Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге бюджетыннан «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлеге Промзона, Әлмәт тракты һәм Полигон ТБО территориясенә алып баручы юл буйларында үлән чабу, чүп җыю буенча эшләрен башкаруга бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплауга

субсидияләр бирү тәртибе турында».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И. Мөхәмәтҗанов